КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 октябрь г.Казань № 892

Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел бклмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 октябрь, 892нче
карары белән расланды

Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели .

2. Субсидияләр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык), әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр алу хокукына түбәндәге критерийларга туры килә торган коммерциячел булмаган оешмалар ия :

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән юридик зат булып тора;

коммерциячел булмаган оешманы гамәлгә куючы - Татарстан Республикасы;

коммерциячел булмаган оешманың устав эшчәнлеге «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзелештә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучылар алдында законнарда билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортлар төзүне гамәлгә ашыручы һәм банкрот дип танылган төзүчеләрнең йөкләмәләрен җайга салуга юнәлдерелгән.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр торган чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр:

коммерциячел булмаган оешма хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәткә түләү буенча түләүләргә исәп-хисапларны исәпкә алып);

төзүче хокукларын һәм бурычларын күчергәндә күчемсез милек объектларын дәүләт теркәве белән бәйле чыгымнар;

счетка банк хезмәте күрсәтү буенча чыгымнар;

судка дәгъва гаризалары биргәндә дәүләт пошлинасын түләү өлешендә суд чыгымнары.

5. Субсидияләр коммерциячел булмаган оешма субсидияләр бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләре булмау;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары булмау;

үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел;

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алучы булып тормый.

6. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешмалар Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган ирекле рәвештә субсидия бирү турында гариза (алга таба - гариза);

штат расписаниесе;

коммерциячел булмаган оешманың югары коллегиаль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт өчен түләү турында нигезләмә;

коммерциячел булмаган оешманың билгеләнгән тәртиптә коммерциячел булмаган оешманың югары коллегиаль органы тарафыннан расланган эшчәнлек планы;

коммерциячел булмаган оешманың югары коллегиаль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган чыгымнар сметасы;

коммерциячел булмаган оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

коммерциячел булмаган оешмага карата үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процедурасын кертү процедураларының булмавы, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгеллеге турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хаты;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгән, һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары булмауны раслый торган документлар;

оешманың Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган, коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хаты.

Документлар кәгазьдә һәм (яки) электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин.

7. Коммерциячел булмаган оешма үз инициативасы буенча түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

субсидия алучы салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләр булмауны раслый торган документ;

Коммерциячел булмаган оешма әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документлардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык гаризаны кабул итүне һәм теркәүне, алар тапшырылган көнне башкара.

Гаризаны кабул итү һәм теркәгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә Министрлык аңа кушып бирелгән документларны карый һәм субсидия бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Коммерциячел булмаган оешмага субсидия бирүдән баш тартуы өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртипнең 3 пункты белән билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бирелгән гаризада һәм документларда булган мәгълүматның дөрес булмавы.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык, карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, коммерциячел булмаган оешмага хәбәр җибәрә.

10. Коммерциячел булмаган оешмага бирелә торган субсидия (С) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P_1 + P_2 + P_3 + P_4$$

монда:

$P_1$ – коммерциячел булмаган оешма хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнары (хезмәт өчен түләү буенча исәп-хисапларны исәпкә алып);

$P_2$ – төзүче хокукларын һәм бурычларын күчергәндә күчемсез милек объектларын дәүләт теркәве белән бәйле чыгымнар;

$P_3$ – счетка банк хезмәте күрсәтү буенча чыгымнар;

$P_4$ – судка шикаять гаризалары биргәндә дәүләт пошлинасын түләү өлешендә суд чыгымнары.

Шул ук вакытта күрсәтелгән чыгымнар түбәндәгечә билгеләнә:

$P_1$ – расланган штат расписаниесе һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 425 статьясында һәм «Производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турында" 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясында билгеләнгән иминият взнослары күләме нигезендә;

$P_2$ – күчемсез милек объектлары саныннан һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 25.3 бүлеге нигезендә билгеләнгән күчемсез мөлкәткә милек хокукларын дәүләт теркәвенә алу өчен түләнергә тиешле дәүләт пошлинасы күләменнән чыгып;

$P_3$ –түләнергә тиешле документлар санына бәйле рәвештә һәм «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзелештә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмага хезмәт күрсәтүче вәкаләтле банк тарафыннан билгеләнгән тарифлар нигезендә»;

$P_4$ – судка гариза биргәндә Россия Федерациясе Салым кодексының 25.3 бүлеге нигезендә билгеләнгән дәгъва таләпләренең планлаштырылган суммасыннан һәм дәүләт пошлинасы күләменнән чыгып.

11. Субсидияләр Министрлык һәм коммерциячел булмаган оешма арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типик форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидияләр күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслау чыганагы булып субсидияләр торган чыгымнар юнәлешләре, субсидияләрне күчерү тәртибе һәм вакытлары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидиядән файдалану турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм өстәмә хисап бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда);

агымдагы финанс елында коммерциячел булмаган оешма тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр калдыкларын кире кайтару очраклары;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары булган чыгымнарны, Министрлык тарафыннан күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, гамәлгә ашыру мөмкинлеге;

коммерциячел булмаган оешманың һәм килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның, Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан коммерциячел булмаган оешма тарафыннан аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмә.

Килешү, Министрлык тарафыннан субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнелгән җиде көн эчендә төзелә.

Кирәк булганда, Министрлык һәм коммерциячел булмаган оешма Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

13. Субсидияләр бирү нәтиҗәсе булып коммерциячел булмаган оешманың билгеләнгән тәртиптә коммерциячел булмаган оешманың югары коллегиаль органы тарафыннан расланган эшчәнлек планын үтәү тора.

14. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә коммерциячел булмаган оешмага субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

15. Субсидия Министрлык тарафыннан коммерциячел булмаган оешманың кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына, килешү төзелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә күчерелә.

16. Коммерциячел булмаган оешма, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, хисап елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, раслый торган документларны теркәп, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында Министрлыкка хисап бирә.

17. Коммерциячел булмаган оешма Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм субсидияне максатсыз файдалану өчен җавап тота.

18. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр калдыклары хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйчаТатарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш, Министрлык тарафыннан әлеге акчаларга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш.

19. Субсидия коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозу;

билгеләнгән срокта субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырмау;

килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәү.

20. Коммерциячел булмаган оешма әлеге Тәртипнең 18 һәм 19 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, Министрлык, субсидия кире кайтарылу срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

21. Бирелә торган субсидияләрнең максатчан кулланылышын Министрлык Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерүдә тота.